ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЧУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӨЧЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2023 Түбән Көчек авылы № 8

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге торак пунктларында чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны, материаллар һәм эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулын билгеләү турында» 17.05.2021 елның 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны алдан юридик тикшерү һәм федераль законнарны мониторинглау, хокукый анализ, хокукый җайга салу юлларын мониторинглау нәтиҗәләре буенча Кодексның АМС системасы - Региональ законнар аналитигы ярдәмендә муниципаль норматив хокукый актка туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты к ар а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге торак пунктларының янгынга каршы яклауны ныгыту максатларында чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны, материалларны һәм эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулын билгеләү турында» 17.05.2021 елның 6 номерлы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендәге мәгълүмати стендта игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Р. А. Нурмөхәммәтов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Көчек авыл
җирлеге Башкарма комитетының
10.03.2023 елның 8 номерлы
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге торак пунктларында чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны, материаллар һәм эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулын билгеләү турында» 17.05.2021 елның 6 номерлы карарына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 4 пунктның 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Торак пунктларның индивидуаль җир кишәрлекләрендә коры үләннәрне, ботакларны, яфракларны һәм башка янучан үсемлекләрне яндыру өчен ачык ут кулланганда, шулай ук бакча яисә яшелчә бакчаларында ачык ут куллану урыны биналарга, корылмаларга һәм башка корылмаларга кадәр кимендә 15 метр ераклыкта урнашырга тиеш;";

2. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.".